**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**СТЕПНООЗЕРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**
423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная, дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИКҮЛЕ**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ НУРЛАТ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 25» март 2024 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 4 апрелендә 10 сәгать 00 минутта М. Горький урамы буенча 13нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында М. Горький урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 4 апрелендә 11 сәгать 00 минутта Совет урамы буенча 14нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында Совет урамы буенча, Клуб урамы буенча, Илюткино авылындагы Җиңү урамы буенча яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Илюткино авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез гражданнар җыенында элек расланган мәсьәләләргә үзгәрешләр кертүгә ризамы;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 18 октябрендәге 1нче номерлы карары

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнар Җыенының 2023 елның 18 октябрендәге 2нче номерлы карарын түбәндәге редакциядә раслап:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илюткино авылындагы торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын салу, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Илюткино авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Би Күле авыл җирлеге башлыгы А.М. Шакирова